СОВЕТ ИШКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Ишкеево,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422161

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИШКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Ишки авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422161

тел.(факс): (85563) 2-41-19; e-mail: Ishk.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар

№ 4-21 | «20» февраль 2023 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советының 2016 елның 17 августындагы «Җирле салымнар буенча недоимканы, әлеге салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» 1-11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 263-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Ишки авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советының 2016 елның 17 августындагы «Җирле салымнар буенча недоимканы, әлеге салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» 1-11 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның исемендә һәм 1 пунктында «Җирле салымнар буенча недоимканы, әлеге салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтүгә өметсез» сүзләрен «җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет-телекоммуникация челтәрендә Мамадыш муниципаль районы http://mamadysh.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Ишки
авыл җирлеге башлыгы | Р.К.Хафизов